ГЛАВА КИЛЬДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.16, с. Кильдеево, 422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 16 нче йорт, Килди авылы, 422586

тел.: (84379) 34-7-41, факс: (84379) 34-7-41.

05.11.2019 № 1

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең Харино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 5 ноябрендә булып узган «2020 елда Килди авыл җирлегенең Харино поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә җибәрү белән килешәсезме» соравы буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

- Харино авылының су башнясының беренче санитар зонасын коймалау һәм төзекләндерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 59 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саныннан 31 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 31 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Харино авыл җирлегендә узган халык җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен-чын дип танырга..

2. "2020 елда Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегендә Харино авылында яшәү урыны буенча Югары Ослан муниципаль районының Харино авылында теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категория гражданнардан тыш, һәр балигъ булмаган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме? – Харино авылының су башнясының беренче санитар зонасын коймалау һәм төзекләндерү.

3. Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең Харино авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Харино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларын теркәүгә җибәрү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В.М.Бурдин